**СОВЕТ ДУБЪЯЗСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422720 Республика Татарстан, Высокогорский район,,
с.Дубъязы, ул.Ленина, д.28

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ДӨБЪЯЗ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422720, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Дөбъяз авылы, Ленин ур.,28

Тел./факс: +7(84365) 61-297, e-mail: Dub.Vsg@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**23 апрель 2024 ел** **№ 85**

**Биектау муниципаль районы Дөбъяз авыл җирлеге Советының “Биектау муниципаль районы Дөбъяз авыл җирлеге депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына карата үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр биргән өчен, әгәр бу белешмәләрне бозу җитди булмаса, җаваплылык чаралары күрү турында карар кабул итү Тәртибе” турында 2020 елның 03 сентябрендәге 171 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Биектау районы прокуратурасының 2024 елның 20 февралендәге 02-08-01 номерлды Протесты нигезендә, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында», 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законнар, 2017 елның 19 июлендәге 57-ТРЗ номерлы «Контракт буенча муниципаль вазыйфа яки җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, контракт буенча муниципаль вазыйфаларны яисә җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тапшырган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү турында» Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Дөбъяз авыл җирлеге Советы,

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Биектау муниципаль районы Дөбъяз авыл җирлегенең “Биектау муниципаль районы Дөбъяз авыл җирлеге депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына карата үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр биргән өчен, әгәр бу белешмәләрне бозу җитди булмаса, җаваплылык чаралары күрү турында карар кабул итү Тәртибе” турында 2020 елның 03 сентябрендәге 171 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 пунктның 2 абазацында “Татарстан Республикасы Президенты” сүзләрен “Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)” сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 3 пунктта “Татарстан Республикасы Президенты” сүзләрен “Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)” сүзләренә алмаштырырга;

1.3. 5 пунктның 2 абазацында “Татарстан Республикасы Президенты” сүзләрен “Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)” сүзләренә алмаштырырга;

1.4. 6 пунктта “Татарстан Республикасы Президенты” сүзләрен “Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)” сүзләренә алмаштырырга;

1.5. в абзацах 1, 3 пункта 7 слова «Президента Республики Татарстан» заменить на «Главы (Раиса) Республики Татарстан»;

1.6. Түбәндәге эчтәлектәге 9.1. пункты белән тулыландырыга:

«9.1. Коррупциягә каршы тору максатларында чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу турындагы таләпләрне һәм бурычларны үтәмәгән өчен дисциплинар җаваплылык билгеләнгән физик зат, әгәр мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәү, шулай ук мондый бурычларны үтәмәү аңа бәйле булмаган тикшерүләр тарафыннан танылса, күрсәтелгән җаваплылыктан азат ителә. Әгәр федераль законнарда башкача билгеләнмәгән булса, Мондый чикләүләр, тыюлар һәм таләпләрне, шулай ук мондый бурычларны үтәү физик зат тарафыннан, мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәүгә комачаулаучы, аңа бәйле булмаган шартлар гамәлдә булмаудан соң бер айдан да соңга калмыйча, тәэмин ителергә тиеш.»

1.7. 11 пунктның 1 абзацында “Татарстан Республикасы Президенты” сүзләрен “Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе)” сүзләренә алмаштырырга

2. Әлеге карарны https://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ адресы буенча «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан (халыкка чыгарылган) көннән үз көченә керә.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы Р.Ш.Галиуллин